**ГЛАВА КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422626 Хәерби авылы,
Горкий урамы, 26а нчы йорт,
тел: 4-38-16

2023 елның 7 ноябре 5 номер

# КАРАР

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең Травкино торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 18 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Травкино авылы, Озерная урамы адресы буенча урнашкан 11а номерлы йорт янында Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең Травкино торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. 2023 елның 18 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Травкино авылы, Березовая урамы адресы буенча төзелә торган кибет янында Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең Травкино торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Травкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- Травкино торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм тоту (Пушкин урамы, Дачная урамы, ташу, вак таш һәм ком салу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, техник күзәтчелек өчен түләү)

Травкино торак пунктында Тынычлык урамында балалар мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Хәерби авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Хәерби**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Зиннәтуллин Р.К.**